# КАРАР
# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советы

Чалпы авылы № 150 «01» август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге 08.05.2014 ел №102-1карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында (17.03.2017 ел № 52 карары нигезендә)

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен билгеләү максатларында

Чалпы авыл җирлеге Советы карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

Чалпы авыл җирлеге 08.05.2014 ел №102-1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибенә (17.03.2017 ел № 52 карары нигезендә), «5. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«5. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе

Үзара салым акчаларын җыю тәртибе Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында : http://aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Мөхәмәтшин